15. Плотникова, А.А. О символике свиста // Мир звучащий и молчащий: Семиотика звука и речи в традиционной культуре славян. – М., 1999. – С. 295–304.
16. Чисталев, П.И. Коми народные музыкальные инструменты. – Сыктывкар: Коми книжное изд-во, 1984. – 104 с.
17. Штейнфельд, Н.П. Бесермяне. Опыт этнографического исследования // Календарь и памятная книжка Вятской губернии на 1895 г. Вятка, 1894. – С. 220–259.
18. Munkácsi, Bernát. Votják népköltészeti hagyományok. Budapest: kiadja a Magyar tudomanyos academia, 1887.

Сабитова Илһамия Исламетдиновна
Сафина Эльвира Ирфатовна
ТР ФА нең Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СОМОКОМПОНЕНТЛЫ ОРНИТОНИМНАР

Авторы на основе накопленного практического и теоретического материала дают краткий анализ орнитонимам с соматическими компонентами в татарском языке.

Ключевые слова: *сомоним, сомонимия, соматизм, соматический термин, орнитоним, орнитологическая лексика, названия птиц.*

On the basis of practical and theoretical material authors give brief analysis to ornithonyms with somatic components in the Tatar language.

Key words: *somonym, somonymy, somatism, somatic term, ornithin, ornithological vocabulary of bird names.*

Соматик лексика дөнья картинасын күзаллау, аңлау өчен әһәмиятле булган лексик төркемнәрдән санала. Соматизмнар төрле лексик берәмлекләр, терминнар һәм бигрәк тә фразеологизмнар составында күп очрый. Моны, беренчедән, әгъза атамаларының лексиканың борынгы тармагын тәшкил итүе, икенчедән, аларның җиңел һәм җайлы метафоралашуы белән аңлатып булыр иде.

А.М. Кочеваткин эрзә теленең соматик лексикасын лингвогеографик анализлауга багышлаган хезмәтендә барлык соматик лексиканы, номинацияләү объектына бәйле рәвештә, түбәндәге төркемнәргә бүлә: сомонимнар (кеше әгъзалары атамалары), остеонимнар (сөяк: баш, гәүдә, очлык сөякләре атамалары), спланхнонимнар (эчке органнар: аш кайнату, сидек-җенес, тын алу органнары атамалары), ангионимнар (кан, лимфа тамырлары, үт юллары), сенсонимнар (күрү, ишетү, сизү органнары атамалары) һәм кеше организмының төрле авыруларын һәм тышкы билгеләрен белдергән лексика [2: 6].

Зур лексик пластны тәшкил иткән һәм киң кулланышта булган кош атамалары арасында соматизм компонентлылары шактый. Бигрәк тә, калькалаштырылган атамалар арасында күп алар. Җыелган материалны

анализлагач, кошларның гәүдәсен кеше гәүдәсе, әгъзалары белән чагыштырып, шуларга охшату, метафоралаштыру юлы белән барлыкка килгән орнитонимнарның сомонимнар (*баш, арка, түш, аяк, корсак һ.б.*), остеоним (*койрык*), сенсионим (*күз*) ярдәмендә ясалуы ачыкланды.

Сан ягыннан иң күп сомокомпонентлы орнитонимнарны *койрык* остеонимы ярдәмендә ясалганнары тәшкил итә. Биредә койрыкның төсе, формасы, зурлыгы алгы планга чыга. Мәсәлән, төс белән бәйле: *кара уткойрык, ак башлы уткойрык, кызылкойрык; аккойрык, аккойрык бөркет* һ.б.; койрыкның формасы, рәвеше белән бәйле (нәрсәгәдер охшаган булуы): *җилпәзә койрыклы кошлар, яссы койрыклы тутый кошлар, чөй койрыклы тутый кош, аерча койрыклы тилгән, мичче энәкойрык, энә койрыклы керәшә, ракета койрыклы күк карга, сәнәк койрыклы акчарлак, кылкойрык // безкойрык, сиртмәкойрык* һ.б.; койрыкның зурлыгы (озын яки кыска һ.б. булуы): *кыска койрыклы тутый кош, озын койрыклы диңгез бөркете, озын койрыклы ябалак, озын койрыклы күке, озын койрыклы песнәк,озын койрыклы каракош, озын койрыклы соры ябалак, кыска койрыклы үләксә акчарлагы, озын койрыклы ясмык чыпчыгы* һ.б. Хәтта, башка кошлар койрыгы белән чагыштырудан туган калькалаштырылган атама да бар: *күке койрыклы һөдһөд*.

Метафорик үсеш-үзгәреш нәтиҗәсендә сомонимнарның мәгънә спектры киңәю нәтиҗәсендә барлыкка килгән кош атамаларына да тукталып үтик. *Баш* сомонимы белән ясалган орнитонимнар, нигездә, башның төсен белдерә торган сыйфатлар белән бергә килә. Ак, кызыл, кара, яшел, көрән һ.б. башлы кошлар күпчелекне тәшкил итә. Мәсәлән: *ак башлы диңгез бөркете, ак башлы таш чыпчыгы, ак башлы сип, ак башлы гриф, ак башлы уткойрык, акбаш; кызыл башлы тукран, кызыл башлы чумгалак; кара башлы чыпчык, кара башлы купшы, кара башлы зур имәнборын, кара башлы көрән песнәк, кара башлы купшы, карабаш шаркылдык, әрәмә карабашы, сары башлы кәрлә чыпчык, җирән башлы лачын, сары башлы чәперчек, зәңгәр башлы асылма тутый кош, яшелбаш, яшел башлы чәперчек,көрән башлы песнәк* һ.б. Моннан тыш, кошларның башын төрле предметлар яисә хайваннар башы белән чагыштыру өчен кулланыла торган сүзләр ярдәмендә ясалган сомокомпонентлы орнитонимнар да очрый: *китбаш*, *чүкечбаш, чүкечбашлылар, мәче башлы ябалак, алмабаш чүрәкәй, алмабаш* (вак үрдәк төре) һ.б.

Борын сомонимы кергән орнитонимнарда, гадәттә, кошлар томшыгының зурлыгын – кечкенәлеген, формасын, төсен һ.б. белдерә торган сүзләр була: *озын борынлы чумгалак, кәкре борынлы шөлди, түгәрәк борынлы йөзәр шөлди, яссы борынлы йөзәр шөлди, көрәкборын, сары борынлы аккош, кызыл борынлы альп каргасы, үрдәкборын, безборын, киңборын, корыборын, имәнборын, кара башлы зур имәнборын, мөгезборынлы зур кош, зур һинд мөгезборыны* һ.б.

Арка сомокомпонентлы орнитонимнар арканың төсен белдергән сыйфатлар ярдәмендә генә ясалган: *сары аркалы чәперчек, ак аркалы тукран, ак аркалы альбатрос, кара аркалы альбатрос, кара аркалы давыл кошы, сары аркалы чебенче* һ.б.

Авыз, аяк компонентлы орнитонимнарнында соматизмның төсен, формасын яки башка үзенчәлеген билгели торган сыйфатлары бар: *киңавыз, киң авызлы күке, киң авызлы көнчыгыш күк каргасы, ябалаксыман бакаавыз,ачык авызлы ләкләк, киң авызлы көнчыгыш каргасы, кыска аяклы шөлди, озын аяклы челән, йөнтәс аяклы ябалак, шәрә аяклы ябалак, энә аяклы ябалак, төкле аяклы ябалак, йөнтәс аяклы йөгерек, кызыл аяклы ибис, агаяк, кызыл аяклы миләш чыпчыгы, кызыл аяклы ибис* һ.б. *Ярымтәпиле казлар* атамасында *тәпи* сомокомпоненты бар.

Бары тик төсне генә белдергән сыйфатлар һәм соматизмнар ярдәмендә ясалган кош атамалары аерым бер зур төркемне тәшкил итә. Мәсәлән, *бил* (*ак билле керәшә*), *корсак* (*аккорсак, ак корсаклы дала күгәрчене, ак корсаклы керәшә, кара корсаклы дала күгәрчене*), *иңсә* (*ак иңсәле диңгез бөркете*), *каш* (*ак кашлы миләш чыпчыгы, кашкалак, сарыкаш, ак кашлы сайрар сандугач* һ.б.), *күкрәк* (*кызыл күкрәкле үләксәашар*), *маңгай* (*ак маңгайлы каз, кара маңгайлы каракош*), *түш* (*актүш, каратүш, күктүш, сарытүш, чуартүш, кызылтүш, карлыгач сыман актүшле каракош, каратүшле чыпчык, кызыл түшле гагара, кызыл түшле казарка, кызыл түшле тургай* һ.б.), *яңак* (*ак яңаклы акчарлак, ак яңаклы казарка, ак яңаклы былбыл, соры яңаклы чумга*) һ.б.

Анализ кош атамаларын ясауда *бармак* (*кыска бармаклы былбыл, өчбармаксыманнар, өч бармаклы акчарлак, өч бармаклы тукран, өчбармак* һ.б.), *колак* (*зур колаклы кыргавыл, зур колаклы ябалак, колаклы ябалак*), *сыйрак* (*озын сыйраклылар*) соматизмнарының да катнашуын күрсәтә.

Муен сомонимы да кош атамалары ясауда продуктив компонентларның берсе булып санала: *еланмуен, гади еланмуен, акмуен, ак муенлы чебенче, кызыл муенлы ком шөлдие, кызыл муенлы чумга, кара муенлы аккош, кара муенлы балкүрсәткеч, муенчаклы солы чыпчыгы, муенчаклы ябалакчык, муенчаклы яр чыпчыгы*.

Шулай ук, *бүксә* атамасы да (*бүксәч күгәрчен, зур бүксәле йөгерек шөлди, кызыл бүксәле казарка, кызыл бүксә, кара бүксәле диңгез казы, кара бүксәле гагара, кызыл бүксәле тургай* һ.б.) орнитонимнар ясауда үзенең продуктивлыгы белән аерылып тора.

Эзләнү-тикшеренү процессында *күз* сенсионимының кош атамалары ясауда шактый актив роль уйнавы күренде: *ак күзле чумгалак, аккүз кошлар, күзлекле бабакош, күзлекле баклан, ак күзле чумгалак,күзлекле гага, көрән янлы аккүзчек* һ.б.ш.

Соматизмнарның алтынчы төркеме – кеше организмындагы төрле авыруларны һәм тышкы билгеләрне белдергән лексика да орнитонимнар

составында күп очрый. Мисал итеп *мыек* (*мыеклы керәшә, мыеклач песнәк, мыеклы песнәк*), *төк* (*төкле аяклы ябалак*), *сакал* (*сакалтәй, сакалтәй кошлар, сакаллы кыңгыраучылар, сакаллы көртлек, сакаллы карчыга, сакаллы гриф, сакаллы ябалак,сакаллы соры ябалак*), *йон* (*йонлач карчыга, йөнтәс аяклы ябалак, йөнтәс аяклы елак карчыга, йөнтәс аяклы йөгерек, йөнтәс озынаяк, йонлач* һ.б.) соматизмнарын китерергә була.

Анализланган фактик материал сомокомпонентлы орнитонимнарның татар телендә махсус специальләшкән термин булудан бигрәк, халык өчен җиңел аңлаешлы гомумлексикасының бер өлеше булып торуын күрсәтә. Мисаллардан күренгәнчә, телебездә сомокомпонентлы орнитонимнар шактый һәм алар арасында күпчелекне *авыз, аяк, баш, койрык, борын, муен, күз* компонентлы кош атамалары тәшкил итә. *Бил, корсак, яңак, сакал, түш* һәм башка соматизмнар кергән орнитонимнар да очрый.

Әдәбият

Богус, З.А. Сомантическая лексика и сомантический язык / З.А. Богус // Культурная жизнь Юга России. – 2007. – N 1. – С. 59-60.

Кочеваткин, А.М. Соматическая лексика эрзянского языка: Учеб. пособие / А.М. Кочеваткин. – Саранск: Тип. «Крас. Окт.», 2001. – 208 с.

Костина, Н.Ю. Названия птиц как специфическая группа слов: Дисс. ... канд. филол. наук: 10.02.01. Орел, 2004. – 280 с.

Мугу, Р.Ю. Полисемантизм соматической лексики (на материале русского и немецкого языков): Дисс. … канд. филол. наук: 10.02.01., 10.02.20. / Адыгейс. гос. ун-т, Майкоп, 2003. – 189 с.

Сафина, Э.И. Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование / Э.И. Сафина. – Казань: Изд-во «Дом печати», 2006. – 160 с.

Симакова, О.Б. Лексико-семантическая группа «Орнитонимы» (на материале русского и французского языков): Дисс. ... канд. филол. наук: 10.02.01., 10.02.19. Пенза, 2003. – 293 с.

Сагдеева Фаузия Кабировна

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, Казань

МОДЕЛИРОВАНИЕ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОГО ПОНЯТИЙНОГО АППАРАТА

В конце XX века в лингвистике формируется новое междисциплинарное направление – лингвокультурология. Основу развития данного направления составляет антропоцентрическая парадигма. Антропоцентрическая парадигма предполагает новый подход к языку как объекту исследования, новые ключевые понятия и терминологию, которая отражает эти понятия и составляет метаязык лингвокультурологии.